**Республика Татарстан**
**Сармановский муниципальный район Карашай Сакловское сельское поселение**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**
**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

---

Совет карары

05 апрель 2023 г. № 67

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы Прокуратурасы 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүмат нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 сентябрендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктына «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге
Советы рәисе В.В.Хосниева